| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ<br>ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ<br>СОСТОЯНИЕМ<br>САМОХОДНЫХ МАШИН И<br>ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ<br>БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ<br>ТЕХНИК ТОРЫШЫНА<br>КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| 11.07.2017 | Казан ш. | 01-05/166-пр |

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп, б о е р ы к б и р ә м:

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Дәүләт техника күзәтчелеге
идарәсе башлыгының 2017
елның 11 июлендәге
01-02/166-пр номерлы
боерыгы белән расланды

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп эшләнде.

Әлеге Тәртип эш бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциясез оешма) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.

Бу Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгы алар өчен эшкә алучының вәкиле булып торган Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан язмача, шушы Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән формада төзелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупциячел һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карау эшен гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гаризаны тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашуының планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соң биш эш көне узганчы Җаваплы зат Гаризаны, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен тапшыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән соңгы ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карар кабул иткән көннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Гаризаның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге мөһере белән таныкланган, башлык резолюциясе куелган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра. Гаризаның Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгы резолюциясе куелган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә кушып куела.

Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең 2017 елның 11 июлендәге 01-05/166-пр номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә 1 нче кушымта

______________________________________________________

______________________________________________________

(Ф.И.А., били торган вазыйфа һәм структур

______________________________________________________

бүлекчә, яшәгән урын адресы

______________________________________________________

телефон номеры)

## Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерцисез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гариза

Миңа (кирәклесенең астына сызарга)________________________________

(иҗтимагый оешманың атальшы,

__________________________________________________________________________________________

торак, торак-төзелеш, гараж кооперативының, яшелчәчелек, бакчачылык

,__________________________________________________________________________________ белән

дача кулланучылар кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең атальшы)

_________________________________________________________________________________________

(бер кеше кулындагы башкарма органның яисә идарә коллегиаль органының атальшы)

_________________________________________________________сыйфатында, түләүсез нигездә идарә итүдә катнашырга, аның коллегиаль идарә органы составына керергә рөхсәт бирүне сорыйм.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ___________________ | ________________________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең 2017 елның 11 июлендәге 01-05/166-пр номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиальидарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы
Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә
рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Үтенеч язуын бирүченең Ф.И.А., вазыйфасы | Үтенеч язуын бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.А. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |